# “У войны не женское лицо...”

## Бәдәмшина Рабига Бәдәмша кызы (1924- 1968)



Кызыл-Йолдыз районы , Юлсубино авылында Яруллин Бәдамша белән Гайшәбикә апа гаиләсендә 5 нче бала булып дөньяга килгән. Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан апасы Шәмсия аны үз янына Владивостокка чакырып ала. Сугышка ул шуннан китә. Бигрәк тә японнарга каршы сугыш хәрәкәтләрен искә алып сөйли торган була.

Сугыштан соң туган якка кайтып урнаша, Кызыл – Йолдыз районында (Котлы Бокәш авылы) авыл советында бухгалтер булып эшли.1953 нче елда следователь Юныс Сәфәргәлиевка кияугә чыга,1955 нче елда уллары Дамир туа.1968 нче елда 44 яшендә сугышта алган яралардан вафат була.

## Яруплина Маһирә Бәдәмша кызы (1922 - 10.08.1958)



Кызыл-Йолдыз районы, Юлсубино авылында Яруллин Бәдамша белән Гайшәбикә апа гаиләсендә 4 нче бала булып дөньяга килгән. 30 нчы елларда әтисенең абыйсы Вафа Маһирәне Казанга алып китә. Маһирә монда рус мәктәбен тәмамлый, соңыннан финансовый институтны бетереп югары белгеч вазифасын ала. Бөек Ватан сугышына 1942 нче елның 11 нче апрелендә Казанның Сталин районы хәрби комиссариатыннан (хәзерге Идел буе районы) китә. 2 нче полк, Аз (аэростат заграждения)да кызылармеец булып хезмәт итә. Украинада бандераларга каршы сугыша. Сугыштан соң Украинада Львовь райкомында баш бухгалтер, экономист булып эшли, партия сафларында була. Ислам Заббаров дигән хәрби белән гаилә корып Әлфия һәм Равилне үстерәләр.Тик сугышта алган җәрәхәтләр тынгы бирми. 1958 нче елның 10 нчы августында Маһирә апа вафат була.